# Әйтеп калыйм

Күп вакытлар үтә шигырь язмый,
Яшәү авыр икән гел моңсыз.
Үз-үзеңнән фикереңне чикләү,
Яшәгән күк икән ул җансыз.

Уңга-сулга бәргәләнә башлыйм,
Сабырлыгым бетсә, бар түзем.
Туган икән, димен, яшәр өчен –
Әйтеп калыйм дөньяга сүзем.

Әйтеп салыйм кеше әйтмәгәнне,
Күңелемдә генә йөрмәсен.
Кеше төрле, ләкин йөрәк сүзе
Һәр телгә дә үтеп керәлсен.

Җан сулышым ничек, сүзләрем дә
Шулай туар, шулай чыгарлар.
Сансызлар бар, ләкин аңламаган,
Уйланмаган җаннар юк алар.

## Йөрәктә – язларның ялкыны!

Күз инде бу якта, күз инде.
Мәхәббәт гөлләре дә шиңде.
Бар җирдә матурлык югалды,
Табигать корыды, җан янды.

Һәркемнең җиһанда үз язы,
Көзе дә яз кебек гел назлы.
Кемгәдер кышта да язлар бар,
Югалса күңленнән чиксез зар.

Күз инде бу якта, көз инде,
Сагнуның барсына түз инде.
Арада йөрсә дә салкыны,
Йөрәктә – язларның ялкыны!

## Шигырь

Шигырь белән кичен ятам,
Шигырь белән уянам.
Төрле уйлар килсәләр дә,
Шигырь диеп ут янам.

Уйлар туа башлый шулай,
Кабат шигырь языла.
Шаулап-гөрләп килеп керәм
Кинәт яшәү языма.

Шигырь күзне ачты минем,
Яшәр өчен дөньяда.
Шигырь кирәкле тормышта
Сиңа да һәм миңа да.

Көзе дә җәй кебек була,
Кышы язга әйләнә.
Ярый шигырь булган җирдә
Күрер өчен бәйрәм дә.

## Юллар озын

Күк елый әле дә,
Кералмый хәлемә,
Өзелеп лә тама тамчысы.
Йөрәктән китте яз,
Күңелдә бетте наз,
Яңгыр – бүген Ходай камчысы.

Кыйнады җаннарны,
Сыйлады каннарны,
Юл газабы – үзе бер гомер.
Калганда юлларда
Ничекләр чыдарга,
Юллар төрле, ләкин ул тик бер.

Язгандыр безләргә
Бары тик түзәргә,
Язмышлар бит Аллаһ кулында.
Яңгырмы, буранмы,
Юлга дип чыкканмы –
Бул түзем син, бул тик юлыңда.

Әгәр яңгыр яуса,
Көчле җилләр чыкса,
Син юлчымы – чыда давылга.
Юллар сине көтә,
Юллар өмет итә,
Юллар озын, ләкин якында!..

## Юл кешесе

Мин әле дә юл кешесе,
Юлларда һәрчак йөрим.
Юлчы гына булуымны
Бәхетсезлек дип белмим.

Үзем сайлаган язмышка
Үзем чумам да чыгам.
Бу тормышның баткагында
Йөрәккә бирсен чыдам.

Түзә белсен горур гәүдә,
Түземлек бирсен Ходай.
Түзә-түзә теткәләнеп
Гомер дә үтте бугай.

Әл дә җан бар яшәр өчен,
Хәрәкәттә аяк-кул.
Юлга чыктым тагын таңнан,
Юлчы йөрәк, исән бул!

## Болытлар

Еракта ук инде болытлар,
Туган якка кайтып баралар.
Кайткач, миннән хәбәр салырлар,
Бәлки, кайтмый туктап калырлар…

Кайту юлы сезгә турыга,
Кайтучының һәрчак юл уңа.
Кайталсагыз әгәр иртәгә,
Сез әйтегез сәлам иркәмә.

Берьялгызым читтә каңгырам,
Туган илне, дусны сагынам.
Безнең якка ага болытлар,
Җаным кала елап, буылыплар…

Кайчан җитәр кайтыр вакытлар,
Булса икән кеше болытлар…
Кайтыр юлым ачык бүгеннән,
Сагынуым йөрәк түреннән…

## Сандугач

Сандугачкай сайрый өздереп,
Алмагачларга кунып.
Сайраулары җырлау кебек,
Күңелләр китә тулып.

Сайрар кошкай җырлаганда
Кызганмый барлык көчен.
Артист хезмәтенә тигез
Җырлары шуның өчен.

Җырла әле, сандугачым,
Өздереп үзәкләрне.
Синең сәхнә – алмагачлар,
Җилкетү тирәкләрне.

Сандугачым, сайра, тынма,
Синдә талант, моңнар бар.
Синең моңны, сирәк җырны
Һәр тыңлаучы олылар…